РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЙДАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Гагарина ул., д. 13 а, д.Айдарово, 422095
тел. (факс): (84360) 5-34-46,
E-mail: Aydar.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЙДАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Гагарин ур., 13 а нче йорт, Айдар авылы, 422095
тел. (факс): (84360) 5-34-46,
E-mail: Aydar.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318091 ОГРН 1061675010825 ИНН/КПП 1619004436/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 20 «18» июля 2023 ел

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 20 нче марты 3нче номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Айдар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Акционерлык җәмгыятьләре турында» 1995 елның 26 декабрендәге 208-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында» 1998 елның 08 февралендәге 14-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 20 нче марты 3нче номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Айдар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында» карарына ( 01.02.2021 №2 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Айдар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына аукцион уздыру тәртибендә:

- 16 пунктның пунктчасында «мөһер белән таныкланган» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Х.Ш. Хәсәншин